ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ ______________ с. Верхний Услон КАРАР ______________

«Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе составындагы муниципаль берәмлекләр педагогик мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы мәгълүмат-методика бүлекләре хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү шартларын раслау турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының 31.03.2022 ел №335 карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 22 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 2 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 29.03.2022 ел № под-583/22 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән Министрлыгының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Муниципаль район мәгариф идарәсе (бүлеге)» муниципаль казна учреждениесе составындагы мәгълүмат-методика бүлекләре хезмәткәрләренең Муниципаль берәмлекләр педагогик мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы хезмәтенә түләү шартлары турындагы үрнәк нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 22.11.2024 ел, № под-1959/24 боерыгы нигезендә, белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча методик ярдәм күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе составындагы муниципаль берәмлекләр педагогик мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы мәгълүмат-методика бүлекләре хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү шартларын раслау турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының 31.03.2022 ел №335 карары белән раасланган «Татарстан

Республикасы Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе составындагы мәгълүмат-методика бүлекләрендә муниципаль берәмлекләр педагогик мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләү шартлары турындагы нигезләмәгә (21.08.2024 №1040, 25.12.2025 №1497 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның 2 бүлегендә түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль берәмлекләрнең мәгариф бүлекләре (идарәләре) структурасындагы мәгълүмати-методик бүлекләр хезмәткәрләренең нигез окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазифа атамасы | Айга төп оклад күләме, сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | аттестацияне уңышлы үткән затка “бакалавр”, “магистр” яисә “дипломлы белгеч” бирү белән расланган югары һөнәри белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Методист | - | - | 22271,0 |
| | | | | |
| Дүртенче квалиф | Өлкән методист | - | - | 22276,0 |
| | | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| икация дәрәҗәсе | | | | |
| | | | | |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Структур бүлек мөдире (начальник) : муниципаль берәмлекләр мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлек; | - | - | 22446,0 |

2. Әлеге карар 2025 елның 1 маеннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының бүлеге» МКУ начальнигына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе
вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Ю. В. Федотова

Әзерләде
Ф. М. Әхмәтова
3 нөсхәдә